ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

08.04.2021 Казан ш. № 50-3/соц-2021

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын актуальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын оештыруның сынау проектында катнашучы Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә күрсәтелә торган социаль хезмәтләргә тарифлар билгеләү турында» 2020 елның 4 мартындагы 8-2/соц-2020 номерлы;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын оештыруның сынау проектында катнашучы Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә күрсәтелә торган социаль хезмәтләргә тарифлар билгеләү турында» 2020 елның 4 мартындагы 8-2/соц-2020 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 июлендәге 8-2/соц-2020 номерлы.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев